КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 декабрь г.Казань № 1161

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1194 нче карары белән расланган 2024 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1194 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 гыйнвар, 8 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 8 ноябрь, 849 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 97 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2024 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планына, 2.33 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.33 | Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрендә ягулык-энергетика ресурсларын куллануның нәтиҗәлелеген даими мониторинглау һәм | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары | Ел саен | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен тәэмин итү | 49,5 | 49,0 | 48,5 | 48,0 | 47,5 | 47,0 | 46,5 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | анализлау | | | өчен гомуми мәйданның 1 кв. метрына электр энергиясенең чагыштырма чыгымы, 1 кв.метрга кВт×ч | | | | | | | |
| | | | | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен тәэмин итү өчен 1 кешегә табигый газның чагыштырма чыгымы, 1 кешегә куб.метр | 169,5 | 169,0 | 168,5 | 168,0 | 167,5 | 167,0 | 166,5». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин